ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КАЕНЛЫК АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422712, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Каенлык авылы, Новостройка ур., 15А

СОВЕТ БЕРЕЗКИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422712, Республика Татарстан, Высокогорский район,
с.Березка, ул. Новостройка, 15А

Тел./факс: +7(84365) 79-2-08, e-mail: Berez.Vsg@tatar.ru

КАРАР
11 ноябрь 2019 ел

РЕШЕНИЕ
№ 25

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Каенлык авыл җирлеге җирле үзидарә органнары тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр Исемлеген раслау турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында”, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясы 1 бүлеге 3 пунктчасы нигезендә, “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Каенлык авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы белән эш йөртеп, Каенлык авыл җирлеге Советы,

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Каенлык авыл җирлеге җирле үзидарә органнары тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр Исемлеген расларга.
2. Әлеге карарны Биектау муниципаль районы рәсми сайтында Интернет челтәрендә http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адресы һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru/ веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Башкаруны контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Совет рәисе,
авыл җирлеге башлыгы И.И.Гатауллин

Кушымта

Расланган
Биектау муниципаль районы
Каенлык авыл җирлеге Советы
карары белән
11.11.2019 № 25

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КАЕНЛЫК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘ ОРГАННАРЫ ТАРАФЫННАН КҮРСӘТЕЛӘ ТОРГАН МУНИЦИПАЛЬ ХЕЗМӘТЛӘР ИСЕМЛЕГЕ**

| № т/б | Муниципаль хезмәт исеме |
|---|---|
| 1. | Адреслар бирү, үзгәртү, юкка чыгару |
| 2. | Документлар күчермәләренең һәм алардан өземтәләрнең дөреслеген аныклау |
| 3. | Нотариаль эшчәнлек башкару: васыятьне аныклау яки ышаныч кәгазен аныклау |
| 4. | Белешмә (өземтә) бирү |
| 5. | Агачларны, куакларны кисүгә, аларның ябалдашларын кисүгә яки утыртуга рөхсәт бирү |
| 6. | Капиталь төзелеш объектын планлаштырылган бетерү турында хәбәрнамә, капиталь төзелеш объекты бетерү тәмамлану турында хәбәрнамә кабул итү |